**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сарлы авылы №109 «25» апрель 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» 11.08.2014 елның 66-26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (16.11.2015 елның № 16-5, 06.12.2016 елның №42-23, 23.04.2019 елның №130-66, 19.02.2020 елның №156-77, 15.03.2021 елның №20, 22.09.2021 елның №35, 31.01.2023 елның №77 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Сарлы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» 11.08.2014 елның 66-26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (16.11.2015 елның № 16-5, 06.12.2016 елның №42-23, 23.04.2019 елның №130-66, 19.02.2020 елның №156-77, 15.03.2021 елның №20, 22.09.2021 елның №35, 31.01.2023 елның №77 карарлар редакциясендә) 4.1 бүлегенең 1 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне,

тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәү турында документлар һәм (яисә) белешмәләр тапшыру.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис И.М. Камалетдинов